**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы**
**Олы Әтнә авыл җирлеге Шекәнәч торак пунктында**
**ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

“19” ноябрь 2023 ел № 2

2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы «Олы Әтнә авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 20 статьясы, «Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда гражданнар җыенын әзерләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» Олы Әтнә авыл җирлеге Советының 25.10.2019 ел №126 карары нигезендә, Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Шекәнәч торак пунктында халык җыены **КАРАР КЫЛДЫ:**

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Шекәнәч авылы территориясендә 2024 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Шекәнәч авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк гражданнардан, 1 төркем инвалидлардан, мобилизацияләнгән гражданнардан һәм аларнын гаилә әгъзаларын, РФ Оборона министрлыгы белән контракт тозегән хәрби хезмәткәрләрдән һәм РФ Оборона министрлыгы белән контракт тозегән хәрби хезмәткәрләрнең гайлә әгъзаларыннан тыш, хәр кешедән 500 сум күләмендә үзара салым акчаларын кертергә.

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтергә:

1) Шекәнәч авылы Пионер һәм Татарстан урамнары территорияләрен төзекләндерү һәм чистарту (үлән кисү, агачлар, куаклар, үсентеләр кисү, кисү материалларыннан һәм чүп-чардан каты көнкүреш калдыклары полигонына кадәр чистарту);

2) Шекәнәч авылы зиратын карап тоту һәм төзекләндерү (үлән кисү, агачлар, куаклар, үсентеләр кисү, кисү материалларыннан һәм чүп-чардан каты көнкүреш калдыклары полигонына кадәр чистарту);

3) Шекәнәч авылынын буаны ремонтлау һәм төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу һәм килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

2022 елда гражданнар җыены белән билгеләнгән буаны ремонтлау һәм төзекләндерү өчен 40000 сум күләмендә гражданнарның үзара салымы кулланылмаган акчаларын түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә :

1) буаны ремонтлау һәм төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу һәм килешү буенча эш һәм хезмәтләр өчен түләү).

3.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлегенең Шекәнәч авылында яшәүче халык җыенының әлеге карарын Олы Әтнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларына урнаштыру юлы белән бастырып чыгарырга.

4.Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Олы Әтнә авыл җирлеге Шекәнәч авылында узган халык җыены карарын Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында" http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Олы Әтнә авыл җирлеге башкарма
комитет җитәкчесе: Порфирьев С.Н.